КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 22 сентябрь г.Казань № 857

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 ел, 5 март, 158 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 11 июль, 566 нчы; 2019 ел, 24 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 17 октябрь, 924 нче; 2019 ел, 8 ноябрь, 1024 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

1 нче пунктта «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

Программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы (алга таба – Программа)»; |

«Программаның дәүләт заказчылары» юлында «Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы» сүзләренә алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1. «2019 – 2025 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру»;<br>2. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре»;<br>3. «2019 – 2025 елларга Татарстан яшьләре»;<br>4. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү»;<br>5. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр дәүләт сәясәтен камилләштерү»;<br>6. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү»;<br>7. «2019 – 2025 елларга Татарстан балалары»;<br>8. «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасының эшче яшьләре»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 24 454 795,6 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 24 408 019,0 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 3 814 902,9 мең сум;<br>2020 елда – 6 664 904,2 мең сум;<br>2021 елда – 2 799 104,9 мең сум;<br>2022 елда – 2 809 846,0 мең сум;<br>2023 елда – 2 773 087,0 мең сум;<br>2024 елда – 2 773 087,0 мең сум;<br>2025 елда – 2 773 087,0 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына караган җирле үзидарә органнарының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән – 46 776,6 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2021 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2022 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2023 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2024 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2025 елда – 7 796,1 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>ял итүнең оештырылган формалары белән җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр санын 221 мең кешегә кадәр;<br>авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 74,1 процентка кадәр;<br>авылны икътисадый үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 5,4 процентка кадәр;<br>яшьләрнең гомуми санында талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшьләрнең өлешен 53 процентка кадәр;<br>патриотик юнәлештәге чаралар белән җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр санын 63 мең кешегә кадәр;<br>министрлык тарафыннан каралган документлар санын бер дәүләт хезмәткәренә 360 берәмлеккә кадәр;<br>модернизацияләнгән яшүсмерләр клублары санын 61 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасы балалар сәламәтләндерү лагерьларында башкарылган капиталь ремонт эшләре санын |

| | |
|---|---|
| | 69 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасы яшьләр үзәкләрендә башкарылган капиталь ремонт эшләре санын 37 берәмлеккә кадәр;<br>балалар һәм яшьләрнең гомуми санында балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары чаралары белән җәлеп ителгән балаларның, яшьләрнең чагыштырма авырлыгын 91,5 процентка кадәр;<br>социаль проектлаштыру, идарә итүне планлаштыру, социаль программалар буенча белем алган предприятиеләрдә һәм оешмаларда эш белән тәэмин ителгән активистлар санын 700 кешегә кадәр;<br>Татарстан Республикасының 100 кешедән артык булган предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшче яшьләр берләшмәләре санын 400 берәмлек күрсәткеченә кадәр;<br>эшче яшьләрнең гомуми саныннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларында катнаша торган эшче яшьләр өлешен 40 процентка кадәр;<br>яшьләрнең гомуми санында ирекleләр эшчәнлегендә катнашучы яшьләр өлешен 26 процентка кадәр»; |

Программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. Программаны тормышка ашыру тармагының гомуми тасвирламасы,
шул исәптән хәл итү өчен Программа юнәлдерелә торган мәсьәләләр

Бу Программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 – 2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы турында» 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карарын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрен раслау турында» 2014 елның 29 ноябрендәге б-2403 номерлы; Балачак унъеллыгы кысаларында 2018 – 2020 елларга төп чаралар планын раслау турында 2018 елның 6 июлендәге б-1375 номерлы, 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә ирекlелек (волонтерлыкны) үстерү концепциясен раслау турында 2018 елның 27 декабрендәге б-2950 номерлы боерыкларын, Россия Федерациясе Президентының балалар ялын үстерү буенча төбәк программаларын эшләү мәсьәләсе буенча 2012 елның 20 августындагы Пр-2215 номерлы һәм балалар савыктыру ялын оештыру мәсьәләләре буенча 2012 елның 24 августындагы 34547-Пр номерлы йөкләмәләре исемлеген, «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республиксында дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 ел, 4 февраль, 63 нче; «Татарстан Республикасында социаль өлкәне һәм иҗтимагый инфраструктураны модернизацияләү һәм үстерү турында» 2016 ел, 3 сентябрь, 614 нче карарларын; «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешмасы тарафыннан эшләнгән 2016 –

2020 елларга Татарстан Республикасында социаль тармакларны һәм иҗтимагый инфраструктураны үстерү концепциясен исәпкә алып эшләнде.

Программада яшьләр чаралары, шул исәптән форумнар, семинарлар, конкурслар, слетлар, профильле сменалар кысаларында Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясендә, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясендә, Россия Федерациясе Президентының 2018 елның 29 июнендәге 378 номерлы Указы белән расланган 2018 – 2020 елларга коррупциягә каршы тору буенча илкүләм планында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 2 август, 569 нчы карары белән расланган 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегиядә булган бурычларны һәм өстенлекләрне гамәлгә ашыру карала.

Программа чаралары Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2018 елның 31 октябрендәге 1288 номерлы карарын, аерым алганда, «Мәгариф» илкүләм проектының «Социаль активлык» федераль проектын, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре комплексында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2019 ел, 20 июнь, 504 нче карарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән.

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен раслау турында» 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы нигезендә, экстремизмга каршы тору субъектларының, гражданлык һәм башка кызыксынучы оешмалар институтларының (яшьләр берләшмәләрен, яшьләр сәясәте челтәре учреждениеләрен кертеп) көчләрен берләштерү бурычларын исәпкә алып, яшьләрнең төрле категорияләре (8 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшүсмерләрне, укучы яшьләрне, предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүче яшьләрне кертеп) белән эшләүнең өстенлекле юнәлешләре буенча Программа чаралары актуальләштерелде. 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы көрәш стратегиясе бурычларын тормышка ашыруда (шул исәптән яшьләрнең аерым яшь һәм социаль категорияләрен социальләштерү шартларын булдыруга һәм аларга ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән ярдәмче программалар кысаларында) Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында, Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп күрсәткечләре системасы бүлеге буларак яшьләр мохитенә экстремизм идеяләренең үтеп керүен профилактикалау буенча субъектларның эшчәнлеген бәяләүне, экстремизмга каршы тору мәсьәләләрен үз эченә алган социологик тикшеренүләр үткәрү өстенлекле юнәлеш булып тора.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2919 ел, 4 март, 149 нчы карары белән расланган 2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясен һәм

Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын үтәү йөзеннән, Программа чаралары арасында Татарстан Республикасы яшьләренең психологик ихтыяҗларын һәм сорауларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең ведомствоара системасын үстерү бурычлары гамәлгә ашырыла.

Дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыру, яшьләр проблемаларын нәтиҗәле хәл итү өчен программа ысулы актив кулланыла.

Тармакара өлкә буларак дәүләт яшьләр сәясәте үзенчәлегенә бәйле рәвештә, яшьләр белән эшләүнең бөтен спектры: мәгариф, эшкә урнашу, патриотик, хокукый тәрбия бирү, үз-үзеңне тормышка ашыру, буш вакыт өчен шартлар оештыру, тискәре социаль күренешләрне профилактикалау, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген формалаштыру буенча ведомствоара яраштыру урнашты.

2018 елда Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының, яшьләр сәясәте субъектларының барлыкка килгән миссиясе – яшьләрнең социаль, иҗади һәм үз-үзләрен һөнәри тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр мохите тудыру. Миссияне тормышка ашыру буенча төп эш принцибы – яшьләр өчен яшьләрсез бернәрсә дә юк. Төп таләпләрдән чыгып, Программа кысаларында Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруда өч төп максатчан билгеләмәләр билгеләнде:

нәтиҗәлелек һәм таләп ителүчәнлек;

яңа коммуникацияләр форматы;

үз-үзеңне тормышка ашыру өчен мохит.

Бу стратегия Программаның мөһим юнәлешләрен билгеләде.

Республикада ял итү өлкәсе турында, эчтәлеге буенча үзенчәлекле булса да, балаларга һәм үсмерләргә тәрбия бирү барышының аерылгысыз бер өлеше буларак күзаллау ныгыды. Республикада балалар һәм яшьләр ялын тәэмин итү эшен оештыру өчен мөмкинлекләрнең чикләнгән булуы һәм максималь сандагы ял итүгә мохтаҗларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү кирәклеге арасында каршылыклар булу шартларында оптималь формаларны табарга омтылу хас.

Балаларның сәламәтлеге социаль-икътисадый, демографик һәм медик-биологик факторларның үзара катлаулы бәйләнешләренең интеграль күрсәткече буларак формалаша, алар арасында экологик хәл начараю, туклану җитәрлек дәрәҗәдә һәм балансны булмау, мәктәптә, гаиләдә балаларны укыту һәм тәрбияләү шартлары һәм технологиясе, гаиләнең икътисадый иминлеген киметүгә һәм җәмгыятьтәге социаль киеренкелеккә бәйле булган стресс йогынтылары, начар гадәтләр таралу иң мөһимнәреннән булып тора.

Әлеге күренешләрне профилактикалау өчен «2019 – 2022 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программасы кысаларында сәламәтләндерү учреждениеләрендә лагерьларга балалар җәлеп итү һәм юнәлешле сменалар оештыру буенча планлы һәм максатчан эш алып барыла.

2020 елның 1 гыйнвары хәленә карата Татарстан Республикасында 3 902,9 мең кеше яши. Шул ук вакытта авыл халкының саны 900,7 мең кеше, ягъни республикадагы барлык халыкның 23,1 процентын тәшкил итә. Авыл яшьләре

(15 яшьтән 29 яшькә кадәрге халык) саны – 164,1 мең кеше, яки Татарстан Республикасындагы барлык яшьләрнең 25 процентын тәшкил итә.

Авыл яшьләре социаль төркем буларак, тулы мәгънәдә әйткәндә, үз социаль хәле юк. Ул барлык проблемалары белән бергә хәзерге заманның барлык яшь буын үсеше дәрәҗәсен чагылдыра торган халыкның яшь төркемен барлыкка китерә. Авылда алар тагы да нык чагылыш тапкан. Авыл җирлегендәге яшьләр мохите арасында ярлылык, тормыш дәрәҗәсенең гомуми начараю, эшкә урнашу өчен шартлар булмавы, мәдәни ихтыяҗларның үсеш алмавы, эмоциональ фәкыйрьлек, үз һәм чит кеше тотышының әхлакый бәяләренең түбән булуы аеруча да кискен чагылыш таба. Моның нәтиҗәсе – иҗади хезмәт эшчәнлегенә игътибар итмәү, җәмгыятьнең торышы өчен җаваплылык кимү, аннан читләшү.

Бүгенге көндә авыл яшьләре арасында проект эшчәнлеген үстерү һәм эшмәкәрлекне үстерү мөһим бурычдан булып тора. Ә моны социаль проектлаштыруга, бизнес-планлаштыруга өйрәтүдән башка башкару мөмкин түгел. Хәзер аны, дистанцион укытудан һәм вебинарлар программасыннан файдаланып, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә эшләргә мөмкин.

Авыл яшьләре алдында торган проблемаларны хәл итү максатларында, «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре» ярдәмче программасы кысаларында Татарстан Республикасы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру буенча чаралар планлаштырыла.

Дәүләт яшьләр сәясәтен алга таба үстерү өчен яшьләр мохитендә булган проблемаларны алга таба хәл итү һәм өстенлекләрне тормышка ашыру таләп ителә, алар «2019 – 2025 елларга Татарстан яшьләре» ярдәмче программасында чагылыш тапты. Бу – яшь лидерларны ачыклау, тәрбияләү һәм үз-үзләрен тормышка ашыру системасын камилләштерү зарурлыгы; яшьләрнең хезмәт активлыгын арттыру һәм республиканың масштаблы иҗади проектларында аның катнашу кирәклеге; төрле категорияләрдәге яшьләр төркемнәрен үстерү өчен тигез башлангыч мөмкинлекләрне, яшьләрне хокукый, коррупциягә каршы аң-белем бирүгә, коррупциягә каршы кыйммәтләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән механизмнарны формалаштыру; милли килешүне ныгыту, демократик институтларны үстерү, гомумроссия гражданлык тәңгәллеген һәм Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы бердәмлеген ныгыту, тискәре социаль күренешләрне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру эшенең нәтиҗәлелеген арттыру. Яшьләр сәясәтенең мөһим юнәлеше булып Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын, шул исәптән Татарстан территориясендә белем бирү оешмаларында белем алучы чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү мәсьәләләрен тормышка ашыру тора.

Татарстан Республикасы яшьләренең кыйммәтле юнәлешләрен формалаштыруда гражданлык-патриотик тәрбия бирүнең роле көчәя, бу «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасында чагылыш тапты, программа чаралары кысаларында түбәндәге юнәлешләр системалаштырыла: патриотик тәрбия бирү системасын модернизацияләү һәм гражданлык үзаңын формалаштыру, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның рухи-әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләре нигезендә гомумроссия гражданлык тәңгәллеген, гражданлык җаваплылыгын, Россия тарихы

өчен горурлык хисен ныгыту, хәрби хезмәт үтү өчен гражданнарны хәрби хезмәткә кадәр әзерләү чаралары, патриотик тәрбия бирү өлкәсендә мәгълүмати, фәнни-теоретик һәм методик тәэмин итү.

Татарстан Республикасының тотрыклы социаль-икътисадый үсешен дәүләт яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән тәэмин итү «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында планлаштырыла.

«2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасы Татарстан Республикасының стационар лагерьлары базасында балаларның тулы кыйммәтле ялы һәм аларны сәламәтләндерү өчен, яшь гражданнарның интеллектуаль, иҗади, спорт потенциалын булдыру, аларны мәдәниятле итеп үстерү, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләренә нигезләнгән яшьләргә тәрбия бирү системасын үстерүгә ярдәм күрсәтү, барлык милләтләргә, этносларга, конфессияләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максаты белән яшәү урыны буенча балаларның һәм яшьләрнең буш вакытын оештыру өчен, шулай ук яшьләр сәясәте учреждениеләренең энергия саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыру күздә тотыла.

Республика балаларының тормыш хәлен һәм сыйфатын яхшырту, балаларның комплекслы үсеше һәм эшчәнлеге өчен уңай шартлар тудыру, яшүсмерләр һәм яшьләр арасында психологик ярдәм күрсәтү һәм профилактикалау системаларын үстерү, тормышта авыр хәлдә калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү, балаларда һәм яшүсмерләрдә гомумроссия гражданлык тәңгәллеген, патриотизм, гражданлык җаваплылыгын, Россия тарихы өчен горурлык хисен формалаштыру, гражданнарның хөрмәтенә, намусына һәм милли дәрәҗәсенә нигезләнгән милләтара аралашу культурасын, шул исәптән яшь буында хокукый белемнәр нигезләрен, коррупциягә каршы фикерләүне, милләтара һәм конфессияара дуслык һәм татулыкны, традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне үстерү өчен «2019 – 2025 елларга Татарстан балалары» ярдәмче программасы юнәлдерелгән.

Эшләүче яшьләрнең иҗтимагый файдалы инициативаларын үстерүгә һәм тормышка ашыруга ярдәм итүгә, Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүче яшьләрнең үз-үзләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләрдә яшьләр белән эшләү нәтиҗәлелеген арттыру механизмнарын формалаштыруга юнәлдерелгән чаралар «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасының эшләүче яшьләре» ярдәмче программасында чагылдырырга планлаштырыла.»;

Программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Программаның төп максаты һәм бурычлары, программа чаралары, көтелә торган соңгы нәтиҗәләр тасвирнамәсе, аны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары

Программаның максаты – Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыру.

Куелган максатка ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, аның иҗади потенциалын

республиканың конкурентлык сәләтен ныгытуда файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартлар тәэмин итү.

2. Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм модернизацияләү.

3. Дәүләт яшьләр сәясәте нәтиҗәлелеген күтәрү.

4. Яшьләр сәясәте учреждениеләре инфраструктурасын ныгыту һәм аларның энергетика нәтиҗәлелеген күтәрү.

5. Яшь буынны комплекслы үстерү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту өчен уңай шартлар тудыру, тормышта авыр хәлдә калган балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү.

6. Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүче яшьләргә карата тормышка ашырыла торган яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру, Татарстан Республикасының эшләүче яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру.

Куелган максатның масштаблылыгы чаралар комплексын эшләүне таләп итә.

Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, аның иҗади потенциалын республиканың конкурентлык сәләтен ныгытуда файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартлар тәэмин итү максатларында «2019 – 2025 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру», «2019 – 2025 елларга Татарстан яшьләре», «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре», «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү», «2019 – 2025 елларга Татарстан балалары», «2019-2025 елларга Татарстан Республикасының эшче яшьләре» ярдәмче программаларын тормышка ашыру карала.

Ярдәмче программаларны тормышка ашыру нәтиҗәләрен тасвирлый торган төп күрсәткечләр булып түбәндәгеләр тора:

ялның оештырылган формалары белән җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр саны 221 мең кешегә кадәр арттыру;

авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгы 74,1 процентка кадәр арттыру;

авылны икътисадый үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгы 5,4 процентка кадәр арттыру;

яшьләрнең гомуми санында сәләтле яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башкарма хакимият органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләр өлешен 53 процентка кадәр арттыру;

балаларны һәм яшьләрне патриотик юнәлештәге чараларга тартуны 63 мең кешегә кадәр арттыру;

балалар һәм яшьләрнең гомуми санында балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары чаралары белән колачланган балалар, яшьләрнең чагыштырма авырлыгы 91,5 процентка кадәр арттыру;

предприятиеләрдә һәм оешмаларда эш белән тәэмин ителгән, социаль проектлаштыру, идарә итүне планлаштыру, социаль программалар буенча белем алган активистлар санын 700 кешегә кадәр арттыру;

Татарстан Республикасының 100 кешедән артык булган предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр берләшмәләре санын 400 берәмлек күрсәткеченә кадәр арттыру;

эшче яшьләрнең гомуми санынннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш программаларында катнашучы эшче яшьләр өлешен 40 процентка кадәр арттыру;

яшьләрнең гомуми санында иреклеләр эшчәнлегендә катнашучы яшьләр өлешен 26 процентка кадәр арттыру.

Татарстан Республикасы халкының сәламәтлеген ныгыту, балаларның һәм яшүсмерләрнең буш вакытын, аларның ялын һәм аларны савыктыруны оештыру, республикада демографик хәлне ныгыту, күзәтүсезлекне, экстремизмны, хокук бозуларны, тәмәке тартуны, алкоголизмны, наркоманияне һәм башка тискәре социаль күренешләрне профилактикалау, шулай ук ягулык-энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалану өчен шартлар тудыру максатларында «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру күздә тотыла.

Әлеге ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелеген мониторинглау өчен түбәндәге үлчәү индикаторлары кулланылачак:

модернизацияләнгән яшүсмерләр клублары саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының капиталь ремонт үткәрелгән балалар сәламәтләндерү лагерьлары саны, берәмлек;

Татарстан Республикасының капиталь ремонт үткәрелгән яшьләр үзәкләре саны, берәмлек.

Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм Программа чаралары буенча финанслау аңа теркәлгән кушымтада китерелгән.

Программаны тормышка ашыруның гомуми вакыты: 2019 – 2025 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда Программаны финанслауның гомуми күләме 24 454 795,6 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 24 408 019,0 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 3 814 902,9 мең сум;

2020 елда – 6 664 904,2 мең сум;

2021 елда – 2 799 104,9 мең сум;

2022 елда – 2 809 846,0 мең сум;

2023 елда – 2 773 087,0 мең сум;

2024 елда – 2 773 087,0 мең сум;

2025 елда – 2 773 087,0 мең сум;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына караган җирле үзидарә органнарының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән – 46 776,6 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;
2020 елда – 7 796,1 мең сум;
2021 елда – 7 796,1 мең сум;
2022 елда – 7 796,1 мең сум;
2023 елда – 7 796,1 мең сум;
2024 елда – 7 796,1 мең сум;
2025 елда – 7 796,1 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

Программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

1 нче ярдәмче программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга балалар һәм яшьләр ялын оештыру» (алга таба – 1 нче ярдәмче программа)»; |

«1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2019 – 2025 елларда 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 11 256 106,4 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 11 209 329,8 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 1 564 760,0 мең сум;<br>2020 елда – 1 607 428,3 мең сум;<br>2021 елда – 1 607 428,3 мең сум;<br>2022 елда – 1 607 428,3 мең сум;<br>2023 елда – 1 607 428,3 мең сум;<br>2024 елда – 1 607 428,3 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2025 елда – 1 607 428,3 мең сум;<br>Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына караган җирле үзидарә органнарының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән – 46 776,6 мең сум, шул исәптән:<br>2019 елда – 0,0 мең сум;<br>2020 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2021 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2022 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2023 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2024 елда – 7 796,1 мең сум;<br>2025 елда – 7 796,1 мең сум.<br>1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«1 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «1 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | Ял итүнең оештырылган формалары белән балаларны һәм яшьләрне җәлеп итү, шул исәптән:<br>2019 елда – 218,7 мең кеше;<br>2020 елда – 221,0 мең кеше;<br>2021 елда – 221,0 мең кеше;<br>2022 елда – 221,0 мең кеше;<br>2023 елда – 221,0 мең кеше;<br>2024 елда – 221,0 мең кеше;<br>2025 елда – 221,0 мең кеше»; |

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 1 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 1 нче ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 11 256 106,4 мең сум тәшкил итәчәк, шулардан:

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 11 209 329,8 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 1 564 760,0 мең сум;
2020 елда – 1 607 428,3 мең сум;
2021 елда – 1 607 428,3 мең сум;
2022 елда – 1 607 428,3 мең сум;
2023 елда – 1 607 428,3 мең сум;

2024 елда – 1 607 428,3 мең сум;

2025 елда – 1 607 428,3 мең сум;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына караган җирле үзидарә органнарының җирле бюджетлары акчасы исәбеннән – 46 776,6 мең сум, шул исәптән:

2019 елда – 0,0 мең сум;

2020 елда – 7 796,1 мең сум;

2021 елда – 7 796,1 мең сум;

2022 елда – 7 796,1 мең сум;

2023 елда – 7 796,1 мең сум;

2024 елда – 7 796,1 мең сум;

2025 елда – 7 796,1 мең сум.

1 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Татарстан Республикасының ял оешмаларында сменаларның дәвамлылыгы, Татарстан Республикасының муниципаль районнары һәм шәһәр округлары яктылыгында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга һәм балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны тәэмин итү өчен Татарстан Республикасының җирле бюджетларына субсидияләр бүлү, министрлыклар буенча 1 нче ярдәмче программаны тормышка ашыруга ассигнованиеләр бүлү аңа теркәлгән 2 нче кушымтада китерелгән.

2020 елга балалар ялын оештыруга хезмәтләр күләмнәре нормативлары һәм 2020 елга муниципаль районнар һәм шәһәр округлары яктылыгында балалар ялын оештыруга хезмәтләр күләмнәре нормативлары 1 нче ярдәмче программага теркәлгән 3 нче кушымтада китерелгән.»;

1 нче ярдәмче программага 1 – 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

2 нче ярдәмче программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре» (алга таба – 2 нче ярдәмче программа)»; |

«2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 2 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 17 966,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда – 4 491,6 мең сум;<br>2020 елда – 4 491,6 мең сум;<br>2021 елда – 4 491,6 мең сум;<br>2022 елда – 4 491,6 мең сум;<br>2023 елда – 0,0 мең сум;<br>2024 елда – 0,0 мең сум;<br>2025 елда – 0,0 мең сум.<br>2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш»; |

«2 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «2 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 2 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешү күздә тотыла:<br>авыл яшьләренең гомуми санында консультацияләрнең барлык төрләрен (индивидуаль, электрон, телефон аша) алган авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 72,7 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында «Татарстан Республикасының Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы эшчәнлегенә җәлеп ителгән 15 яшьтән 30 яшькә кадәр яшьләрнең чагыштырма авырлыгын 84,8 процентка кадәр;<br>43 муниципаль берәмлектәге депутатларның гомуми санында депутатларның җирле советларындагы авыл яшьләре өлешен 5,2 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында социаль проектлаштыру буенча белем алган авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 26,5 процентка кадәр; |

| | |
|---|---|
| | авыл яшьләренең гомуми санында авылны социаль үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 74,1 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында бизнесны планлаштыру нигезләре буенча белем алган авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 36,7 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында авылны икътисадый үстерү программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 5,6 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында һөнәри юнәлеш бирү чараларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 83,4 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында интеллектуаль-иҗади чараларга җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 80,2 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында физкультура-сәламәтләндерү чараларына җәлеп ителгән авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 75,6 процентка кадәр;<br>авыл яшьләренең гомуми санында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру программаларында катнашучы авыл яшьләренең чагыштырма авырлыгын 91,3 процентка кадәр»; |

2 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге җиденче абзацында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

2 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 2 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 2 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 17 966,4 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 4 491,6 мең сум;
2020 елда – 4 491,6 мең сум;
2021 елда – 4 491,6 мең сум;
2022 елда – 4 491,6 мең сум;
2023 елда – 0,0 мең сум;
2024 елда – 0,0 мең сум;
2025 елда – 0,0 мең сум.

2 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.»;

2 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан яшьләре» ярдәмче программасында (алга таба – 3 нче ярдәмче программа):

3 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

3 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче проект-граманың исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан яшьләре» (алга таба – 3 нче ярдәмче программа)»; |

«3 нче ярдәмче программаның бурычлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «3 нче ярдәмче программаның бурычлары | Укучы һәм студент яшьләренең хезмәт активлыгының нәтиҗәле модельләрен (шул исәптән икенчел эш белән тәэмин итү һәм студентлар хезмәт отрядлары системасы аша) үстерү өчен шартлар тудыру, яшь буынның инновацион потенциалын һәм эшмәкәрлек активлыгын үстерү;<br>яшь буынның иҗтимагый-сәяси активлыгын һәм гражданлык компетентлыгын формалаштыру;<br>яшьләр мохитендә гражданлык-патриотик тәрбия бирү, милли үзаң һәм толерантлык (Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте стратегиясе нигезендә) системасын үстерү;<br>ирекләләр эшчәнлегендә яшьләр катнашу өчен шартлар тудыру, ирекләлекнең оештырылган формаларына ярдәм күрсәтү («Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә);<br>яшьләр иҗтимагый оешмалары, хәрәкәтләре, яшьләрнең лидерлык сыйфатларын үстерү һәм яшьләр һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары инициативасы белән социаль әһәмиятле проектларга ярдәм итү өчен шартлар тудыру;<br>сәләтле балаларны һәм яшьләрне эзләү, аларга ярдәм күрсәтү, аларның интеллектуаль һәм иҗади потенциалын үстерү өчен шартлар тудыру;<br>яшьләр мохитендә тискәре социаль күренешләрне профилактикалауның нәтиҗәле системасын формалаштыру һәм тормышка ашыру;<br>яшьләр мохитендә экстремизм һәм терроризм идеяләре күренешләрен (Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясе нигезендә) профилактикалау; |

| | |
|---|---|
| | республика яшьләрен бөтендөнья бергәлегенә интеграцияләү максатларында төбәкара һәм халыкара яшьләр хезмәттәшлеген үстерү һәм алмашу;<br>дәүләт яшьләр сәясәтен фәнни-методик, мәгълүмати һәм кадрлар белән тәэмин итү;<br>Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлек өчен шартлар тудыру»; |

«3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 3 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 6 500 676,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 872 568,2 мең сум;<br>2020 елда – 992 375,6 мең сум;<br>2021 елда – 919 433,8 мең сум;<br>2022 елда – 929 074,8 мең сум;<br>2023 елда – 929 074,8 мең сум;<br>2024 елда – 929 074,8 мең сум;<br>2025 елда – 929 074,8 мең сум.<br>3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«3 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «3 нче ярдәмче программа мак- | 3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек |

| | |
|---|---|
| сатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | бирәчәк:<br>студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәтендә катнашучы яшь кешеләр өлешен 5,8 процентка кадәр;<br>яшьләрнең гомуми санында иреклеләр эшчәнлегендә катнашучы яшь кешеләр өлешен 26 процентка кадәр;<br>яшьләрнең гомуми санында сәләтле яшьләргә ярдәм күрсәтү өлкәсендә башкарма хакимият органнары тарафыннан тормышка ашырыла торган проектларга һәм программаларга җәлеп ителгән яшь кешеләр өлешен 53 процентка кадәр;<br>иҗтимагый-сәяси активлык һәм гражданлык компетентлыгы буенча чараларда катнашучы яшь кешеләр өлешен 6,1 процентка кадәр;<br>гражданлык-патриотик юнәлештәге чараларда катнашучы яшьләрне җәлеп итүне 52 мең кешегә кадәр;<br>талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән конкурсларда катнашучы яшьләрне җәлеп итүне 51 процентка кадәр;<br>тискәре социаль күренешләрне профилактикалауга юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләрне җәлеп итүне 5,2 процентка кадәр;<br>яшьләр экстремизмын профилактикалау чараларына җәлеп ителгән яшь кешеләр санын 21 мең кешегә кадәр;<br>төбәкара һәм халыкара яшьләр хезмәттәшлеге өлкәсендә чаралар санын 15 берәмлеккә кадәр;<br>дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә әзерләнгән докладлар, аналитик, фәнни-тикшеренү, методик эшләр санын 5 кә кадәр;<br>дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә һөнәри осталык буенча республика конкурсында катнашучы белгечләр санын 30 кешегә кадәр;<br>дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсе хезмәткәрләренең һөнәри осталык буенча бөтенроссия конкурсында катнашучы белгечләр санын 6 кешегә кадәр;<br>Яшьләр көненә багышланган чараларда катнашучылар санын 2 100 кешегә кадәр;<br>яшьләрнең гомуми санында балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы яшь кешеләр өлешен 60,5 процентка кадәр»; |

3 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 3 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру тармагының гомуми тасвирламасы, шул исәптән хәл итү өчен ярдәмче программа юнәлдерелгән мәсьәләләр

Республикада дәүләт яшьләр сәясәте стратегик мәсьәләләр рәтенә керә һәм яшьләрнең социальләшүе һәм үз-үзен тормышка ашыруы, аның потенциалын үстерү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән эзлекле, тотрыклы үсә торган чаралар

системасы булып тора. Республикада этаплап институциялаштерү процессы гамәлгә ашырылды, нигездә яңа типтагы яшьләр учреждениеләре инфраструктурасы барлыкка килде, дәүләт яшьләр сәясәтенең мәҗбүри характеры турында иҗтимагый фикер формалаштырылды.

Яшьләр сәясәтенең өстенлеге – ул яшьләрнең социаль, иҗади һәм профессиональ үсеше өчен мөмкинлекләр мохите булдыру. Төп эш принцибы – яшьләрдән башка яшьләр өчен бернәрсә дә юк. Төп куелган билгеләмәләрдән чыгып, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруда өч төп максатчан билгеләмәләр билгеләнде:

нәтиҗәлелек һәм таләп ителүчәнлек;

яңа коммуникацияләр форматы;

яшьләрнең үз-үзен тормышка ашыру өчен мохит.

Алар Ярдәмче программаны тормышка ашыруның мөһим юнәлеш-ләрен һәм механизмнарын билгеләде.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 29 ноябрендәге б-2403 номерлы боерыгы белән 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт яшьләр сәясәте нигезләре расланды.

Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру елларында дәүләт һәм яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга сала торган заманча норматив-хокукый база булдырылды. Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең норматив-хокукый базасын формалаштыру өчен «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы, «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 7 апрелендәге 29-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында»2016 елның 4 февралендәге 63 номерлы карары нигез булып тора.

Республикада дәүләт яшьләр сәясәтен үстерүнең 25 елдан артык чорында тормыш эшчәнлегенең төрле аспектлары буенча яшьләр хокукларын тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән барлыгы 260 якын норматив хокукый акт кабул ителде, алар арасында:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының махсус дәүләт стипендияләрен аспирантлар, адъютантлар, студентлар, дәүләт курсантлары, шул исәптән хәрби хезмәткәрләр өчен һәм хосусый мәгариф оешмаларының белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе булган махсус дәүләт стипендияләрен гамәлгә кую турында» 1998 елның 3 мартындагы ПУ-168 номерлы, «Татарстан Республикасында яшь галимнәргә дәүләт ярдәмен көчәйтү чаралары турында» 2002 елның 24 декабрендәге ПУ-1153 номерлы, «Созвездие-Йолдызлык» республика фестиваль хәрәкәтенә ярдәм чаралары хакында» 2006 елның 29 апрелендәге ПУ-165 номерлы указлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Яшьләр сәясәте өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү кыйммәте нормативлары һәм исемлеге турында»

2010 елның 9 декабрендәге 1015 нче, «Җирле үзидарә органнары тарафыннан яшьләр сәясәте өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын раслау хакында» 2011 ел, 21 июнь, 494 нче; «Татарстан Республикасында яшьләр хокук саклау хәрәкәтен үстерү турында» 2012 ел, 30 октябрь, 924 нче; «2020 елга кадәрге чорда Татарстан Республикасында яшьләр ирекле хәрәкәтен үстерү һәм аңа булышлык күрсәтү концепциясен раслау турында» 2014 ел, 27 февраль, 124 нче; «2030 елга кадәр Татарстан Республиксында Дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 ел, 4 февраль, 63 нче; «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасында студентлар һәм яшьләр хезмәт отрядлары эшчәнлеген үстерү концепциясен раслау турында» 2018 ел, 17 гыйнвар, 11 нче; «2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасын формалаштыру һәм үстерү концепциясен һәм Татарстан Республикасында халыкка психологик ярдәм күрсәтү системасы субъектларының ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2019 ел, 4 март, 149 нчы карарлары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшьләр сәясәте өлкәсендә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы учреждениеләр төрләренең исемлеген раслау турында» 2012 ел, 3 ноябрь, б-1986 номерлы боерыгы.

Ярдәмче программаның чаралары Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт илкүләм сәясәте стратегиясен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 елның 2 августындагы 569 номерлы карары белән расланган 2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча стратегияне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясен 2025 елга кадәр раслау турында» 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясе бурычлары нигезендә актуальләштерелде.

Ярдәмче программа чаралары планында Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәрге чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указын, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2018 елның 31 октябрендәге 1288 номерлы карарын, аерым алганда «Мәгариф» илкүләм проектының «Социаль активлык» федераль проектын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2009 елның 20 июнендәге 504 номерлы карарын гамәлгә ашыру чаралары Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре комплексында каралган.

Тармакара өлкә буларак дәүләт яшьләр сәясәте үзенчәлекләреннән чыгып, яшьләр проблемаларының барлык спектры: мәгариф, эшкә урнашу, буш вакытны оештыру, тискәре социаль күренешләрне профилактикалау буенча ведомствоара координацияләү көчәйде.

Яшьләр инфраструктурасы ныклап урнашып килә. Аның составына түбәндәге республика учреждениеләре керә: «Татарстан Республикасы Яшьләр үзәге», «Яшьләр, инновацион һәм профилактик программалар буенча республика үзәге»,

«Сәләтле балалар белән эшләү буенча «Созвездие – Йолдызлык» республика үзәге», «Студентлар хезмәт отрядларының республика үзәге», «Сәләт» яшьләр үзәге», «Идел» яшьләр үзәге», «Җәмәгать тәртибен саклау буенча «Форпост» яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге», «Балалар һәм яшүсмерләр ялы, аларны сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү буенча «Җәй» республика үзәге», «Черноморец» республика үзәге», «Спорт-патриотизм һәм яшьләрне хәрби хезмәткә кадәр әзерләү буенча «Патриот» республика үзәге, «Идел» яшьләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениеләре.

Татарстан Республикасының кайбер муниципаль берәмлекләрендә дәүләт яшьләр сәясәте буенча республика учреждениеләренең филиалларын оештыру мәсьәләләре карала. Россиядә иң эреләрнең берсе булган экстремаль спорт төрләре комплекслары – Казан шәһәрендәге «УРАМ» экстрим-паркы төзелеше алып барыла.

Татарстан Республикасының яшьләр инфраструктурасы 350дән артык учреждениене үз эченә ала: яшьләр өчен 11 республика учреждениесе, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә 224 яшьләр (яшүсмерләр) клубы, 30 яшьләр үзәге, 2 хәрби-патриотик эшләр һәм яшьләрне хәрби хезмәткә кадәр әзерләү үзәге, 7 балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге, 3 балалар һәм яшьләр өчен телефон буенча ашыгыч психологик ярдәм күрсәтү үзәге, студентлар хезмәт отрядлары эшчәнлеген оештыру буенча 10 үзәк (шул исәптән 3 – муниципаль учреждениеләр формасында), җәмәгать тәртибен саклау буенча 40 муниципаль яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге, 119 стационар балалар сәламәтләндерү лагере эшли.

Дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыру, яшьләр проблемаларын нәтиҗәле хәл итү өчен программа ысулы актив кулланыла.

«Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 октябрь, 888 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру шактый социаль нәтиҗәгә ия. Алар нигезендә 12 меңнән артык яшь гаиләгә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтелде.

Казан шәһәрендә төбәктә иң эре «Патриот» яшьләргә патриотик тәрбия бирү буенча республика үзәге ачылды, ул төрле оешмалар һәм ведомстволарның, хәрби комиссариатлар, ветераннар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларының эшчәнлеген яраштырырга мөмкинлек бирә.

Программа алымы кысаларында яшьләр сәясәтенең авыл яшьләре белән эшләү, коммерциягә карамаган яшьләр һәм балалар оешмаларына, иреклелеккә, студентлар хезмәт отрядларына, талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү кебек юнәлешләр актив үсеш ала, шулай ук тискәре социаль күренешләрне профилактикалау һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча эшләү системасы формалаша.

Россия җәмгыятенең хәзерге вакыттагы хәле, социаль-икътисадый трансформацияләр, яңа сәяси чынбарлыклар, массакүләм мәгълүмат чараларың экспансиясе халыкның рухи рәвешенә сизелерлек йогынты ясый, күп кенә идея-әхлакый

ориентирларны, җитештерүләрне яңадан карау һәм яңа рухи кыйммәтләрне үзләштерү процессларын стимуллаштыра. Хәзерге вакытта уенга һәм интернетка бәйлелек арту; десоциализация, виктимность, көчләү, агрессия, хокукка каршы гамәлләр һәм яшьләрнең антисоциаль үз тотышы күренешләре; экстремистлык һәм террорчылык юнәлешендәге тискәре субкультуралар арту, психоактив матдәләрне куллануга җәлеп итү; суицидаль үз тотыш; җенси тормышны иртә башлау; этникара киеренкелек һәм милләтара конфликтлар; төрле мәдәният һәм төрле яшь төркемендәге кешеләр аралашуында толерантлыкны киметү һ.б. кебек төрле куркынычлар актуальләшә.

Яшьләрнең социаль-психологик киеренкелеге дәрәҗәсен минимальләштерү һәм психологик сәламәтлеген ныгыту максатларында, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы халыкка психологик ярдәм күрсәтүнең ведомствоара системасын үстерү буенча координацияләү үзәге буларак тора, аның эшчәнлеге Татарстан Республикасы яшьләренең барлык спектрдагы психологик ихтыяҗларын һәм сорауларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән.

«Җәмәгать тәртибен саклау буенча «Форпост» яшьләр (студентлар) формированиеләре үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 1 316 отрядтан торган яшьләр хокук саклау хәрәкәте үсеш алды, яшьләр арасында 903 отрядны үз эченә алган волонтерлык, ирекледәр хәрәкәте, 216 отрядтан торган һәм 10 меңнән артык студентны колачлаган студентлар хезмәт отрядлары хәрәкәте сизелерлек активлашты.

Проект алымы форматында хәзерге шартларда дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда республика яшьләр һәм балалар оешмалары актив катнаша. Республика яшь буынының арткан активлыгы һәм гражданлык өлгереше турында җәмәгать оешмалары һәм берләшмәләре чараларында актив катнашучы яшьләр саны артуны дәлилли, ул яшь буынның гомуми саныннан 50 процентын тәшкил итә. Иҗтимагый оешмалар республика конкурслары, слетлар, фестивальләр, яшьләр форумнары үткәрү инициаторлары булып тора. Алар арасында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы, «Татарстан Республикасы Студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы, «Татарстан Республикасы Иҗади яшьләр академиясе» иҗтимагый оешмасы, «Ватан» берләшмәсе, Балалар һәм яшьләр оешмалары советы, «Татарстан Республикасы сәнәгать предприятиеләре яшьләре» иҗтимагый оешмасы, 40 меңнән артык волонтерның иҗтимагый активлыгын координацияләүче «Татарстан Республикасының Иреклелекне үстерү үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы, Татарстан Республикасы яшь галимнәре һәм белгечләренең яшьләр иҗтимагый хәрәкәте, 90 меңгә кадәр кешене үз эченә алган «Созвездие – Йолдызлык» масштаблы фестиваль хәрәкәте, «Татарстан Республикасының Аграр яшьләр берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы аеруча актив эшли. Интеллектуаль яшьләр хәрәкәте оештырылды һәм үсә.

Татарстан Республикасында ирекледәр хәрәкәте эшчәнлегендә актив катнашучы яшьләр саны арта, ирекледәр активлыгы диапазоны киңәя – агымдагы эшчәнлеккә табигый һәм тарихый мирас һәйкәлләрен саклау, халыклар арасында тынычлыкны һәм татулыкны популярлаштыру һ.б. чаралар кертелгән. Муниципаль дәрәҗәдә иреклелекне үстерү өчен җаваплылык үзәкләре формалаштырыла.

Халыкара яшьләр элемтәләре сизелерлек киңәйде, бу турыда «Яшьләр диалогы: Ислам конференциясе оешмасы – Россия» халыкара конференциясе,

Мөселман яшьләре фестивале, республика яшьләренең Европа Советы, G8 һәм G20 яшьләр саммитларында катнашуы сөйли.

Дәүләт яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүчеләрнең гомуми саны 2 меңгә якын кеше тәшкил итә. Бу өлкәнең кадрлар составы – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, республика муниципаль берәмлекләрендә идарәләр һәм бүлекләр, ведомство буйсынуындагы республика учреждениеләре, яшүсмерләр клублары, яшьләр үзәкләре, балалар сәламәтләндерү лагерьлары, социаль яшьләр хезмәтләре җитәкчеләре һәм белгечләре. Яшьләр белән эшләүче белгечләрнең квалификациясен күтәрү, аларны әзерләү һәм яңадан әзерләү системасы булдырылды.

Республиканың һәм Россиянең алдынгы галимнәре белән хезмәттәшлек итеп, дәүләт яшьләр сәясәтен фәнни яктан тәэмин итү гамәлгә ашырыла. 30дан артык социологик тикшеренүләр үткәрелде, аларның нәтиҗәләре реформалашып килүче җәмгыятьтә яшьләрнең ролен, кыйммәтле ориентирларны һәм сәяси өстенлекләрне, яшьләр мохитендә этномәдәни процессларны, авыл һәм эшче яшьләр проблемаларын чагылдыра.

Шулай итеп, республикада яшь буынга карата дәүләтнең эчке сәясәтенең мөстәкыйль юнәлеше формалашты һәм үсеш ала.

Дәүләт яшьләр сәясәтен алга таба үстерү өчен яшьләр даирәсендә булган проблемаларны хәл итү таләп ителә:

1. Яшьләр лидерларын ачыклау, тәрбияләү һәм үз-үзләрен тормышка ашыру системасын камилләштерү зарурилыгы.

2. Татарстан Республикасы яшьләренең кыйммәти ориентирларын формалаштыруда гражданлык-патриотик тәрбия бирүнең ролен көчәйтү.

3. Яшьләрнең хезмәт активлыгын арттыру һәм аны иҗади проектларга яшьләр арасында тискәре социаль күренешләрне профилактикалау инструменты буларак җәлеп итү зарурилыгы.

Хәзерге вакытта продукция җитештерү күләмнәрен арттыру, яңа җитештерү куәтләрен кертү, республикада масштаблы төзелеш кадрларга ихтыяҗның тиешле дәрәҗәдә артуына китерә. Бүгенге көндә Татарстан Республикасында яшьләр саны 869 мең кеше тәшкил итә. Яшьләрнең өчтән бер өлеше диярлек – 280 мең кеше – югары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм һөнәри белем бирү оешмалары студентлары. Яшьләрне икенчел эш белән тәэмин итүне оештыру, башлап җибәрүче белгечләр белән кызыксынучы эш бирүчеләрне җәлеп итү белән Студентлар хезмәт отрядларының республика үзәге шөгыльләнә. Әмма икътисадның төрле тармаклары яшь хезмәт ресурсларын тигез дәрәҗәдә кабул итми, яшьләрне республика сәнәгать предприятиеләренә җәлеп итү һәм яшьләрнең хезмәт активлыгын җитәрлек дәрәҗәдә стимуллаштыру белән кыенлыклар килеп чыга.

Республикада сәләтле һәм талантлы балаларга, яшьләр-студентларга ярдәм күрсәтү өчен уңайлы шартлар тудырылган. Әмма составына авыл яшьләре, эшче яшьләр, урта һөнәри класс һәм эшмәкәрләр кергән яшьләрнең социаль төркемнәре тормыш-көнкүреш мәсьәләләрен хәл итүдә һәм һөнәри формалашуда кыенлыклар кичерә. Бу проблемаларны хәл итү өчен фән, иҗат, мәгарифнең төрле өлкәләрендә талантлы яшьләргә ярдәм күрсәтү чаралары комплексын эшләү таләп ителә.

14 яшьтән 24 яшькә кадәр наркомания белән авыручылар саны акрын темплар белән (2,95 процент) кими. Республиканың 26 шәһәр һәм районында балигъ булма-

ганнар арасында җинаятьчелекнең 3,9 процентка артуы күзәтелә, балигъ булмаган җинаятьчеләрнең шактый өлеше – укучыларның шактый өлеше (61 процент). Яшьләр арасында тәмәке тарту һәм исерткеч эчемлекләр, сыраны кирәгеннән артык куллану киң таралган. Үсмерләр һәм яшьләр җинаятьчелеге яшерен характер ала башлады.

Болар барысы да тискәре социаль күренешләрне профилактикалауны нәтиҗәле үстерүне һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруны таләп итә, ул превентив чаралар, тормышта авыр хәлдә калган «риск төркемендәге» балалар һәм яшьләр белән эшләү, яшәү урыны буенча тулы кыйммәтле буш вакытны һәм тәрбия эшләрен оештыру, күп санда яшьләрне профилактик эшләргә җәлеп итү кебек эш юнәлешләрен үз эченә алырга тиеш.

Яшьләр арасына милли, раса, дини экстремизм һәм ксенофобия идеологиясе үтеп керүгә каршы тору бары тик системалы гамәлләр, ягъни җәмгыять һәм дәүләт, дини конфессияләрне координацияләү һәм аларның үзара хезмәттәшлеге, шулай ук яшьләр оешмаларының актив позициясе ярдәмендә генә мөмкин.

Экстремизм һәм терроризм күренешләрен контрольдә тоту һәм мониторинглау, алар буенча оператив эш үткәрү – хокук саклау структуралары эшенең өстенлеге. Үз функцияләреннән чыгып һәм Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы белән расланган 2020 елга кадәр Россия Федерациясендә Экстремизмга каршы тору стратегиясе нигезендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы профилактик эшкә игътибарын юнәлтә. Аның бурычы – яшьләрне социаль яктан алга этәрү, деструктив күренешләргә каршы тора белүче яшь буын шәхесен формалаштыру өчен шартлар тудыру.

Яшьләрне социаль яктан алга этәрү, деструктив күренешләргә каршы тора белүче, тормышка сәләтле яшь буын шәхесләрен формалаштыру эшен традицион, тикшерелгән эш формаларын гамәлгә ашыру юлы белән төзергә кирәк, алар арасында:

дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре буенча республика яшьләр программаларын, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 16 октябрь, 764 нче карары белән расланган, әлеге юнәлештә конкрет эш рәвешләре һәм технологияләре чагылдырылган «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» дәүләт программасының «2014 – 2022 елларга Татарстан Республикасында террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру;

республиканың 400 меңгә якын бала һәм яшьләрне үз эченә алган балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегенә булышлык күрсәтү;

яшьләрне социаль әһәмияткә ия республика һәм федераль чараларда катнашуга җәлеп итү, алар арасында Республика яшьләр форумы, «Мәгънәләр территориясе» бөтенроссия яшьләр белем бирү форумы, «Таврида» яшь мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре форумы, «iВолга» округ яшьләр форумы, «Безнең Татарстан» республика яшьләр форумы, «Сәләт» халыкара мәгариф форумы бар. Моннан тыш, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан халыклары ассамблеясы һәм аның яшьләр бүлеге белән берлектә, «Милләтләр лигасы» спартакиадасын, милли командалар арасында КВН турнирларын үткәрә;

милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне алга таба үстерү, яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүне көчәйтү. Казан шәһәрендә XXVII Бөтендөнья җәйге универсиаданы үткәрү Россиядә һәм Татарстанда студентлар спортын үстерү өчен генә түгел, ә халыкара яшьләр хезмәттәшлеген, иҗтимагый дипломатияне сыйфаты ягыннан яңа дәрәҗәдә үстерү, этникара мөнәсәбәтләрне ныгыту һәм яшьләр арасында мәдәниятара диалог үстерү өчен дә уникаль мөмкинлекләр ачты. Бүгенге көндә Татарстанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитеты, Ислам хезмәттәшлеге оешмасы, Европа Советы һәм башка оешмалар белән мондый чараларны уздыру буенча бай тәҗрибә бар.»;

3 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге 4 пунктында «(«Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 15 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә)» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге утыз икенче абзацында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

3 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 3 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 3 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 6 500 676,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 872 568,2 мең сум;
2020 елда – 992 375,6 мең сум;
2021 елда – 919 433,8 мең сум;
2022 елда – 929 074,8 мең сум;
2023 елда – 929 074,8 мең сум;
2024 елда – 929 074,8 мең сум;
2025 елда – 929 074,8 мең сум.

3 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

3 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасында (алга таба – 4 нче ярдәмче программа):

4 нче ярдәмче программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

4 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирү» (алга таба – 4 нче ярдәмче программа)»; |

«4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 4 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 46 281,9 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 16 131,9 мең сум;<br>2020 елда – 10 050,0 мең сум;<br>2021 елда – 10 050,0 мең сум;<br>2022 елда – 10 050,0 мең сум;<br>2023 елда – 0,0 мең сум;<br>2024 елда – 0,0 мең сум;<br>2025 елда – 0,0 мең сум.<br>4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләме ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«4 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «4 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләр | Республикасында патриотик тәрбия бирү инфраструктурасын модернизацияләү:<br>патриотик клубларда (берләшмәләрдә) булган балалар һәм яшьләр санын арттыру (2025 ел – 42 мең кеше);<br>патриотик юнәлештәге чараларда балалар һәм яшьләр катнашуны арттыру (2025 ел – 63 мең кеше);<br>яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү эшен камилләштерү:<br>хәрби-спорт юнәлешле патриотик сменалар санын арттыру (2025 ел – 66 смена);<br>хәрби-спорт лагерьларында әзерлек үткән балалар һәм яшьләр |

| | |
|---|---|
| | санын арттыру (2022 ел – 6 200 кеше);<br>патриотик тәрбия бирү өлкәсендә әзерләнгән белгечләр санын арттыру (2025 елга – 700 кеше, 100 кеше ел саен);<br>яшьләрнең рухый-әхлак культурасы дәрәҗәсен күтәрү:<br>гражданлык бердәйлеге дәрәҗәсен күтәрү;<br>Ватанны саклау бурычын үтәүгә әзерлек дәрәҗәсен күтәрү;<br>яшьләрне хәрби хезмәткә әзерләү эшен камилләштерү»; |

4 нче ярдәмче программаның I бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«I. 4 ярдәмче программа хәл итүгә юнәлдерелгән
проблеманың тасвирламасы

Әлеге 4 нче ярдәмче программа Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 3 февралендәге б-134 номерлы боерыгы белән расланган 2020 елга кадәр чорга Россия Федерациясе гражданнарын хәрби хезмәткә әзерләүнең федераль системасы концепциясе һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 30 декабрендәге 1493 номерлы карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Россия Федерациясе гражданнарына патриотик тәрбия бирү» дәүләт программасы нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт илкүләм сәясәте стратегиясе, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 29 маендагы 344 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә экстремизмга каршы тору стратегиясе бурычларын гамәлгә ашыру максатларында эшләнгән.

4 нче ярдәмче программа Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 7 февраль, 73 нче карары белән расланган «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү» дәүләт программасының «2014 – 2018 елларга Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү» ярдәмче программасының логик дәвамы һәм аны үстерү булып тора, аның төп максаты – республикада патриотик тәрбия бирү системасын булдыру.

Әлеге 4 нче ярдәмче программа барлыкка килгән системаны камилләштерүгә юнәлдерелгән, патриотик тәрбия бирүнең киң спектрдагы проблемаларын чишүдә дәүләт структураларының һәм иҗтимагый оешмаларның (берләшмәләрнең) уртак эшчәнлеген киңәйтүне күздә тота һәм алга таба бу процессны динамикада тотырга ниятли. 4 ярдәмче программа гражданлык үзаңын, патриотизмны, гражданлык җаваплылыгын, Россия тарихы өчен горурлык хисен формалаштыруга, гражданнарның намусын һәм милли абруен, Россиянең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен хөрмәт итүгә нигезләнгән милләтара аралашу культурасын тәрбияләүгә, балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән иҗтимагый инициативаларга ярдәм күрсәтүгә, шулай ук Россия тарихын фальсификацияләү омтылышларын кисәтүгә юнәлдерелгән.

4 нче ярдәмче программа чаралары яшьләрнең барлык категорияләрен социальләштерү өчен шартлар тудыруга һәм яшь буынның аерым яшь һәм социаль

категорияләренә ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыруга, яшьләр арасында экстремизм һәм террорчылык идеяләре үтеп керүне профилактикалауга, социологик тикшеренүләр үткәрүгә, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә, югары белем бирүче мәгариф оешмаларында, һөнәри белем бирү оешмаларында, Татарстан Республикасы предприятиеләрендә һәм оешмаларында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген мониторинглау системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Республикада патриотик тәрбия бирү системасының төп элементы булып республика дәүләт хакимияте органнарын һәм муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын, фәнни һәм мәгариф учреждениеләрен, иҗтимагый оешмаларны (берләшмәләрне), иҗади берлекләрне ведомствоара хезмәттәшлек принципларында берләштерүче патриотик тәрбия бирүнең формалаштырылган инфраструктурасы тора.

Әлеге инфраструктурада әйдәп баручы роль патриотик юнәлештәге балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә ярдәм күрсәтүне һәм үстерүне, үзара хезмәттәшлекнең өстәмә рәвешләрен һәм механизмнарын булдыруны күздә тота торган хакимият институтларына карый. Нәкъ менә алар җәмгыятькә яшьләрнең, гаиләләрнең, гражданлык җәмгыяте институтларының, бизнесның, чиркәүнең патриотик тәрбия бирү нәтиҗәлелеген арттыру зарурлыгы турында сигналлар бирә.

Безнең республикада патриотик тәрбия бирү инфраструктурасының әйдәп баручы звеносы – «Патриот» спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә чакыру алдыннан әзерләү буенча республика үзәге» дәүләт автоном учреждениесе (алга таба – Үзәк). Үзәк патриотик юнәлештәге чараларны, спорт ярышларын һәм җыеннарын оештыру, Ватанны саклаганда һәлак булган сугышчылар истәлеген мәңгеләштерү, кадетлар мәгарифен үстерү, эзләү хәрәкәтен үстерү, яшьләрне армия хезмәтенә әзерләү, патриотик тәрбия өлкәсендә төрле категория белгечләре өчен программалар, курслар һәм җыемнар эшләү бурычларын хәл итә.

Үзәк «Россия ветераннар берлеге» гомумроссия ветераннар оешмасының «Татарстан Республикасы Ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы, Татарстан Республикасының «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы (алга таба – «Ватан» берләшмәсе), Татарстан Республикасының ДОСААФ төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасының Хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе каршындагы патриотик эш буенча координация советы, Татарстан Республикасының Югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы Тәрбия эшләре буенча проректорларның координация советы, Татарстан Республикасы урта һөнәри белем бирү учреждениеләре җитәкчеләренең методик берләшмәсе һәм башкалар белән ведомствоара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырып, патриотик юнәлешле республика структураларының эшчәнлеген килештерә.

Яшәү урыны буенча патриотик эшләр республиканың 400дән артык яшьләр учреждениесе, шул исәптән яшәү урыны буенча 224 яшьләр (яшүсмерләр) клубы, шуларның 84 – патриотик юнәлештәге, 30 яшьләр үзәге, 2 хәрби-патриотик эш һәм яшьләрне яшьләрне хәрби хезмәткә чакыру алдыннан әзерләү үзәге, җәмәгать

тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең 40 муниципаль үзәге, 119 стационар балалар сәламәтләндерү лагере тарафыннан оештырыла.

Үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирүнең, Татарстан Республикасы яшьләрен яшьләрне хәрби хезмәткә чакыру алдыннан әзерләүнең мөһим элементы булып 2015 елның октябрендә Россия Федерациясе Оборона министры С.К.Шойгу инициативасы белән оештырылган «Юнармия» бөтенроссия хәрби-патриотик хәрәкәте тора. Хәрәкәтнең максаты – яшьләргә хәрби-патриотик тәрбия бирү системасын камилләштерү, яшь буында Россия тарихына, аның геройларына, күренекле гражданнарга карата кызыксыну уяту. Хәрәкәт отрядлары, белем бирү оешмалары базасында секцияләр һәм түгәрәкләр эше алып барыла, анда яшь армиячеләр башлангыч хәрби әзерлек нигезләрен үзләштерә, лидерлык күнекмәләрен үстерә, фәнни-техник компетенцияләрне өйрәнә. Яшь дипломатия мәктәбе, яшь корреспондент мәктәбе һәм өстәмә белем бирүнең башка берләшмәләре дәресләрендә, махсус белем һәм күнекмәләр алып, булачак һөнәрне дә билгеләргә мөмкин.

Татарстан Республикасында яшь армия хәрәкәте 2016 елның 7 июлендә оештырылды. «Юнармия» хәрәкәтенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге 2019 елга Россиядә активистлар саны буенча икенче урында нык тора, анда 19 меңнән артык катнашучы исәпләнә.

Патриотик тәрбия бирүне оештыру үз нәтиҗәләрен бирә һәм иҗтимагый яшьләр һәм балалар оешмалары белән бергә эшләү нәтиҗәсендә яшьләрнең күп өлешен колачлый. Яшьләрне патриотик тәрбия бирүгә җәлеп итүдә балалар һәм яшьләр оешмаларына грант ярдәме зур этәргеч булды.

Яшьләргә патриотик тәрбия бирүдә һәм тискәре социаль күренешләрне профилактикалауда «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча яшьләр (студентлар) формированиеләренең республика үзәге мөһим роль уйный. Республика шәһәрләрендә һәм районнарында 1 316 «Форпост» отряды эшли, аларда 17 меңнән артык кеше катнаша.

Патриотик тәрбия бирү эшенә Татарстан Республикасы уку йортлары актив кушылды. Татарстан Республикасының югары уку йортлары ректорлары советы каршындагы Тәрбия эшләре буенча координация советы тәрбия эшенең өстенлекләрен формалаштыра һәм билгели, ул Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты белән берлектә югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаган гражданнарны хәрби хезмәткә чакыруны тәэмин итү буенча комплекслы чаралар планын эшли.

Патриотик тәрбия бирүдә музейлар кебек социаль институт та җәлеп ителгән. Бүген Татарстан Республикасында 1 000 нән артык туган якны өйрәнү мәктәп музее исәпләнә, аларның һәркайсында Бөек Ватан сугышы ветераннары, халкыбызның батырлыклары турында экспозицияләр бар. «Казан Кремле» дәүләт тарих-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы» дәүләт учреждениесе территориясендә урнашкан Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы, «Патриот» спорт-патриотика һәм яшьләрне хәрби хезмәткә чакыру алдыннан әзерләү буенча республика үзәге» дәүләт автоном учреждениесендә эзләү хәрәкәте музее патриотик тәрбия бирү үзәкләренә әверелде. Музейларда ветераннар, тыл хезмәтчәннәре белән очрашулар, хәрби дан һәм истәлекле даталарга багышланган чаралар уза, аларда төп

катнашучылар – Казан Суворов хәрби училищесында, кадетлар корпусында тәрбияләнүчеләр, хәрби хезмәткәрләр, мәктәп укучылары, студентлар, хезмәт коллективлары хезмәткәрләре.

Бүгенге көндә республиканың барлык муниципаль берәмлекләре диярлек хәрби частьләр белән хезмәттәшлек турында килешүләр төзеде, алар кысаларында социаль әһәмияткә ия чаралар актив гамәлгә ашырыла. Татарстанның күп кенә хәрби хезмәткә чакырылучылары республиканы шефлык элемтәләре берләштергән хәрби частьләрдә хезмәт итәргә теләүләре очраклы түгел.

Патриотизм формалаштыру системасының мөһим элементы булып яшьләр белән эшләүнең төрле юнәлешләре, формалары һәм методлары тора: хәрби-спорт уеннарын, Бөек Ватан сугышы һәм локаль сугышлар ветераннары белән очрашулар, строй җыры буенча смотр-конкурслар, батырлык дәресләрен, «Хәрби хезмәткә чакырылучылар көне» шәһәр һәм республика акцияләрен, ел саен «Аҗаган» хәрби-спорт уенын уздыру.

Республиканың рухи яктан үсеш алган яшь буынын тәрбияләү системасында дәүләт символларын куллану зур әһәмияткә ия. Безнең республикада спорт ярышлары, хәрби-патриотик чаралар үткәрү дәүләт флагларын күтәрүдән һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы гимннарын башкарудан башлана. Дәүләт символикасы элементлары шулай ук чаралар үткәрү урыннарын, мәгълүмати һәм презентация материалларын рәсмиләштергәндә дә кулланыла.

Шуңа да карамастан, җәмгыятьтә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм камилләштерү буенча социаль сорау саклана, бу исә әлеге өлкәдә 4 нче ярдәмче программаны озайтуны таләп итә.

Татарстан Республикасында патриотик тәрбия бирү системасына дәүләт ярдәме күрсәтү яшьләр арасында тискәре тенденцияләр үсешенә комачаулый, әмма, яшьләр фикеренчә, хәзерге вакытта гамәлдәге патриотик тәрбия бирү системасы инфраструктурасын модернизацияләргә кирәк. Республиканың яшь буын вәкилләре фикеренчә, патриотик тәрбия бирү белән шөгыльләнүче яшьләр учреждениеләрен үстерү һәм модернизацияләү, белем бирү учреждениеләрендә патриотик тәрбия бирүнең сыйфатын яхшырту, барлык кызыксынучы структураларны патриотик тәрбия бирүдә катнашуга җәлеп итү зарури.

Шулай итеп, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29 ноябрендәге б-2403 номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт яшьләр сәясәте нигезләрендә өстенлекле бурычларның берсе – ул яшьләрне эзләү, археология, хәрби-тарихый, туган якны өйрәнү, студентлар отрядлары һәм яшьләр берләшмәләренең актив эшенә җәлеп итү.

4 нче ярдәмче программаның төп чаралары планын формалаштырганда тормышта авыр хәлдә калган яшүсмерләрне һәм яшьләр субкультураларында катнашучыларны социаль уңай тәҗрибәгә, шул исәптән: хәрби-тактик уеннарга һәм берләшмәләргә, хәрби-тарихый реконструкцияләргә, эзләү хәрәкәтенә җәлеп итү юнәлеше исәпкә алынды.

Россия Федерациясендә 2020 ел Россия Федерациясе Президентының 2019 елның 8 июлендәге 327 номерлы Указы белән Хәтер һәм дан елы дип игълан ителде. Хәтер һәм дан елы кысаларында федераль һәм төбәк дәрәҗәсендәге төп чараларның төп максаты – Бөек Ватан сугышы вакыйгалары һәм анда катнашучылар

турында тарихый хәтерне саклап калу. Бүгенге көндә эзләү эшчәнлеге, беренче чиратта, тарихны фальсификацияләү фактларына каршы торуның иң нәтиҗәле механизмы булып тора. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе субъектларының эзләү отрядлары Ватанны саклаганда һәлак булганнарның язмышларын билгеләү, тыныч тормыш халкының гәүдәләрен – 1941 – 1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында Германия гаскәрләренең хәрби җинаятьләре корбаннары мәетләрен эксгумацияләү буенча экспедицияләрдә актив катнаша. Программа чаралары Татарстан Республикасының эзләү отрядлары тарафыннан муниципаль берәмлекләр яшьләре арасында мәгълүмати һәм агарту эшләрен алып бару өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Яшьләр актив һәм аеруча хәрәкәтчән социаль категория булып тора, аның игътибарын җәлеп итү өчен даими рәвештә кызыклы эш формаларын һәм ысулларын тәкъдим итәргә кирәк. Моңа бәйле рәвештә хәрби-тактик уеннар һәм экстремаль спорт төрләре зур популярлык казанган.

Хәрби-тактик уеннар яшьләрне хәрби хезмәткә чакырганга кадәр Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә әзерләүгә бәйле гражданлык-әхлакый һәм патриотик тәрбия бирүне гамәли тормышка ашыру формасы булып тора, гамәлдә хәрби хезмәт белән танышырга, алга таба хезмәт иткәндә кирәк булачак гамәли күнекмәләр һәм осталыкларны белергә, физик әзерлек дәрәҗәсен күтәрергә, характерны чыныктырырга һәм үз көчләрен сынарга мөмкинлек бирә.

Спортның экстремаль төрләре яшьләрдә зур кызыксыну уята. Елдан-ел экстремаль спорт тарафдарлары саны арта, моңа сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм дөньяда барлык спорт төрләрен популярлаштыру ярдәм итә. Әмма югары хәвеф-хәтәр белән бәйле спорт төрләренең популярлыгына карамастан, республикада максатчан социомәдәни эшчәнлек буларак экстремаль ял итү бик үк үсеш алмаган. Спортның субмәдәни төрләренә үз тотышның социаль формаларына караган стереотиплы мөнәсәбәт бар, бу тулаем алганда экстремаль спорт төрләренә тискәре мөнәсәбәт тудыра.

Программада тормышка ашырыла торган чаралар җәмгыятьтә спортның экстремаль төрләренә уңай мөнәсәбәт формалаштыруга, формаль булмаган яшьләрне патриотик юнәлештәге эшчәнлеккә һәм иҗади эшчәнлеккә җәлеп итүгә, үсеп килүче буынның гражданлык-патриотик аңын формалаштыру өчен комплекслы шартлар тудыруга, Ватанга тугрылык тәрбияләүгә, конституциячел бурычларны үтәүгә әзерлек формалаштыруга юнәлдерелгән.

Җитештерү предприятиеләре һәм оешмаларының хезмәт коллективлары патриотик тәрбия бирү процессына тиешле дәрәҗәдә катнашмый. Патриотик юнәлештәге иҗтимагый оешмалар һәм яшүсмерләр клубларының саны арту аларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүдә системалы якын килүне һәм максатчан ярдәм күрсәтүне таләп итә.

Яшьләргә рухи-әхлакый тәрбия бирүдә дәүләтнең төп партнеры булып традицион диннәр булырга мөмкин, чөнки алар күпбалалы гаилә, үз сәламәтлегенә һәм үз балаларының сәламәтлегенә сакчыл мөнәсәбәт, аларның әхлакый тәрбиясе, патриотизм, үз Ватанына хезмәт итәргә әзер булу, тугрылык, намуслылык, хезмәт сөючәнлек, өлкәннәргә карата хөрмәт, картлар һәм авырулар турында кайгырту кебек социаль кыйммәтләрне формалаштыруда мөһим роль уйный. Дини

берләшмәләр белән берлектә, яшьләр өчен белем бирү, тәрбия бирү һәм реабилитация проектлары мөмкинлекләре кулланылмый. Гражданнарга патриотик тәрбия бирүгә массакүләм мәгълүмат чараларын, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре мөмкинлекләрен активрак җәлеп итү актуаль булып кала.

Яшьләрдә Ватанга хезмәт итәргә әзерлек формалаштыру җитди һәм озак вакытлы эш таләп итә. Россия Федерациясе Кораллы көчләрен реформалау һәм армиядә хезмәт иткән яшь кешеләр өчен социаль ташламалар һәм белем бирү-карьера преференцияләрен тәэмин итү, шулай ук яшьләрнең гражданлык әхлакый-этип аспектын формалаштыруга уңай йогынты ясый алачак.

Соңгы елларда яшьләр арасында үсә торган маргиналь субкультураларның күптөрлелеге күзәтелә. Яшьләр даирәсендә, бигрәк ачыктан-ачык фашистик һәм милли характердагы, экстремистик күренешләр Татарстанда һәм тулаем җәмгыятьтә социаль һәм милләтара тотрыклылыкка куркыныч янарга мөмкин. Россия тикшеренүләре ксенофобия (беренче чиратта, этнофобия һәм мигрантофобия) арту тенденциясен һәм яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә социаль һәм шәхесара ышаныч һәм толерантлык дәрәҗәсе кимүен билгеләп үтә. Республиканың уку йортларында да җитешсезлекләр бар: респондентларның 19,5 проценты гына аларның уку йортларында экстремизмны профилактикалау буенча чаралар үткәрелүен күрсәткән. Күпчелеге исә мондый чаралар белән таныш түгел.

Патриотик тәрбия бирү системасын үстерү өчен бу өлкәдә белемнәрне камилләштерү, патриотик тәрбия бирүнең матди-техник базасын модернизацияләү, аны оештыру-методик яктан тәэмин итү дәрәҗәсен күтәрү, оештыручыларның һәм патриотик тәрбия бирү белгечләренең һөнәри әзерлек дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт коллективларында патриотик тәрбия бирү системасын үстерү, бу эшкә массакүләм мәгълүмат чараларын тагы да активрак һәм киң җәлеп итү һәм патриотик тәрбия бирү бурычларын хәл итү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре мөмкинлекләрен киңрәк файдалану зарури.

Мәгариф учреждениеләре һәм мәдәният учреждениеләре методик яктан тәэмин итүдә, бигрәк тә патриотик тәрбия бирү өлкәсендә белгечләр әзерләү һәм яңадан әзерләү, яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә толерантлык, тынычлык сөючәнлек, социаль татулыкка ирешү, социаль агрессиягә, милли конфликтларга, экстремизмга, терроризмга каршы тору программаларын гамәлгә кертү өлешендә кыенлыклар кичерә. Хәзерге шартларда патриотик тәрбия бирү буенча кайбер закон һәм норматив актларны, аерым алганда, террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау буенча эшләп бетерүнең актуальлеге саклана – моңа сораштырылучыларның 39,7 проценты күрсәтә. Төрле типтагы һәм төрдәге мәгариф учреждениеләрендә физик тәрбия бирү программаларының дәвамчанлыгы юк. Спортның хәрби-гамәли төрләре җитәрлек үсеш алмаган.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында патриотик тәрбия бирү системасын үстерү комплекслы һәм системалы якын килүне, ягъни әлеге проблеманы хәл итүнең программлы-максатчан ысулын куллануны таләп итә.

Программалы-максатчан ысул белән куелган проблеманы хәл итүнең түбәндәге төп өстенлекләрен аерып күрсәтергә мөмкин:

проблеманы хәл итүгә комплекслы якын килү. 4 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру максатлары, бурычлары һәм төп юнәлешләре Татарстан Республикасында яшьләргә патриотик тәрбия бирүнең төрле аспектларын исәпкә ала;

вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлешү. 4 нче ярдәмче программа кысаларында Татарстан Республикасының башкарма хакимият органнары арасында вәкаләтләрне төгәл бүлү үткәрелә. 4 нче ярдәмче программада җирле үзидарә органнарына һәм төрле оешмаларга катнашырга тәкъдим ителә. Әлеге алым программа чаралары үтәлешенең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк;

4 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен мониторинглау һәм нәтиҗәле планлаштыру. 4 нче ярдәмче программа кысаларында теге яки бу чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен ел саен бәяләргә мөмкинлек бирү торган күрсәткечләр билгеләнә. Бу проблеманы хәл итүнең программалы-максатчан ысулы конкрет проектларны гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирәчәк, югыйсә Татарстан Республикасында патриотик тәрбия бирү системасы нәтиҗәле була алмый.

Болар барысы да эшне дәвам итү һәм патриотик тәрбия бирүнең барлык проблемалары комплексын программа ысуллары белән хәл итүгә юнәлдерелгән гамәлләрне координацияләү кирәклеген күрсәтә.»;

4 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 4 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 4 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 46 281,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 16 131,9 мең сум;
2020 елда – 10 050,0 мең сум;
2021 елда – 10 050,0 мең сум;
2022 елда – 10 050,0 мең сум;
2023 елда – 0,0 мең сум;
2024 елда – 0,0 мең сум;
2025 елда – 0,0 мең сум.

4 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм ел саен агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

4 нче ярдәмче программага 1, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 5 нче ярдәмче программа):

5 нче ярдәмче программаның исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

5 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен камилләштерү» (алга таба – 5 нче ярдәмче программа)»; |

«5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 5 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 5 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 266 444,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда – 50 172,0 мең сум;<br>2020 елда – 34 452,8 мең сум;<br>2021 елда – 35 483,8 мең сум;<br>2022 елда – 36 583,9 мең сум;<br>2023 елда – 36 583,9 мең сум;<br>2024 елда – 36 583,9 мең сум;<br>2025 елда – 36 583,9 мең сум.<br>5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«5 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә | 5 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>министрлык тарафыннан каралган документлар санын 1 дәүләт хезмәткәренә 360 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы |

| | |
|---|---|
| торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Премьер-министры, Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарлары йөкләмәләренең гомуми күләмендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан әлеге затлар тарафыннан үтәлү вакыты билгеләнгән тикшерү вакытларында үтәлгән әлеге йөкләмәләр өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы законнарында, Татарстан Республикасы Президенты указларында, боерыкларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларында, боерыкларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең гомуми санында Татарстан Республикасының әлеге норматив хокукый актларында бирелгән шәхсиләштерелгән йөкләмәләрнең Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәлү өлешен 100 процентка кадәр»; |

5 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 5 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 5 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 266 444,2 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 50 172,0 мең сум;
2020 елда – 34 452,8 мең сум;
2021 елда – 35 483,8 мең сум;
2022 елда – 36 583,9 мең сум;
2023 елда – 36 583,9 мең сум;
2024 елда – 36 583,9 мең сум;
2025 елда – 36 583,9 мең сум.

5 нче ярдәмче программаны финанслау күләме фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

5 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа):

6 нчы ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

6 нчы ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» (алга таба – 6 нчы ярдәмче программа)»; |

«6 нчы программаны тормышка ашыру вакытлары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «6 нчы программаны тормышка ашыру вакытлары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 6 нчы ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 6 280 138,7 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда – 1 289 607,4 мең сум;<br>2020 елда – 3 990 531,3 мең сум;<br>2021 елда – 200 000,0 мең сум;<br>2022 елда – 200 000,0 мең сум;<br>2023 елда – 200 000,0 мең сум;<br>2024 елда – 200 000,0 мең сум;<br>2025 елда – 200 000,0 мең сум.<br>6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«6 нчы ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «6 нчы ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 6 нчы ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>модернизацияләнгән яшүсмерләр клублары санын 61 берәмлеккә кадәр;<br>Татарстан Республикасының капиталь ремонт үткәрелгән балалар сәламәтләндерү лагерьлары санын 69 берәмлеккә |

| | |
|---|---|
| (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | кадәр;<br>Татарстан Республикасының капиталь ремонт үткәрелгән яшьләр үзәкләре санын 37 берәмлеккә кадәр;<br>яшьләр сәясәте учреждениеләрен тәэмин итү өчен электр энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – 1 кв.метрга 67,48 кВт × сәгать;<br>яшьләр сәясәте учреждениеләрен тәэмин итү өчен җылылык энергиясенең чагыштырма чыгымы (җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга исәпләгәндә) – җылытыла торган 1 кв.метр мәйданга 0,1376 Гкал;<br>яшьләр сәясәте учреждениеләрен тәэмин итү өчен салкын суның чагыштырма чыгымы (1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) исәпләгәндә) – 1 кешегә (персонал һәм йөрүчеләргә) 0,181 куб.метр;<br>яшьләр сәясәте учреждениеләрен тәэмин итү өчен табигый газның чагыштырма чыгымы (газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына исәпләгәндә) – газ белән җылытыла торган мәйданның 1 кв.метрына 30,31 куб.метр;<br>Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының мәҗбүри энергетика тикшерүен үткән ведомство буйсынуындагы учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр;<br>Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының исәпкә алу приборлары белән җиһазландырылган ведомство буйсынуындагы учреждениеләре (урыннарны арендага алучы учреждениеләрне исәпкә алмыйча) өлешен 100 процентка кадәр»; |

6 нчы ярдәмче программаның II бүлегендәге егерме җиденче абзацта «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

6 нчы ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 6 нчы ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 6 нчы ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 6 280 138,7 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2019 елда – 1 289 607,4 мең сум;
2020 елда – 3 990 531,3 мең сум;
2021 елда – 200 000,0 мең сум;
2022 елда – 200 000,0 мең сум;
2023 елда – 200 000,0 мең сум;

2024 елда – 200 000,0 мең сум;

2025 елда – 200 000,0 мең сум.

6 нчы ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

6 нчы ярдәмче программага 1 нче һәм 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елга Татарстан балалары» ярдәмче программасында (алга таба – 7 нче ярдәмче программа):

7 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

7 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан балалары» (алга таба – 7 нче ярдәмче программа)»; |

«7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «7 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм финанслау чыганаклары буенча бүлеп, 7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | 2019 – 2025 елларда 7 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 45 726,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2019 елда – 11 272,0 мең сум;<br>2020 елда – 11 484,8 мең сум;<br>2021 елда – 11 484,8 мең сум;<br>2022 елда – 11 484,8 мең сум;<br>2023 елда – 0,0 мең сум;<br>2024 елда – 0,0 мең сум;<br>2025 елда – 0,0 мең сум.<br>7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«7 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «7 нче ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 нче ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>18 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләрнең законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча һөнәри ашыгыч психологик ярдәм алган балалар һәм яшьләр өлешен 1,59 процентка кадәр;<br>7 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар һәм яшьләрнең гомуми санында яшәү урыны буенча учреждениеләр эшенә җәлеп ителгән балалар һәм яшьләр өлешен 64,02 процентка кадәр;<br>балалар һәм яшьләрнең гомуми санында балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары чараларына җәлеп ителгән балалар һәм яшьләрнең чагыштырма авырлыгын 91,5 процентка кадәр»; |

7 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге алтынчы абзацында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

7 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 7 нче ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 7 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 45 726,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда – 11 272,0 мең сум;
2020 елда – 11 484,8 мең сум;
2021 елда – 11 484,8 мең сум;
2022 елда – 11 484,8 мең сум;
2023 елда – 0,0 мең сум;
2024 елда – 0,0 мең сум;
2025 елда – 0,0 мең сум.

7 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

7 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2019 – 2022 елларга Татарстан Республикасының эшче яшьләре» ярдәмче программасында (алга таба – 8 нче ярдәмче программа):

8 нче ярдәмче программа исемендә «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

8 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның исеме | «2019 – 2025 елларга Татарстан Республикасының эшче яшьләре» (алга таба – 8 нче ярдәмче программа)»; |

«8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2019 – 2025 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 8 нче ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, 8 нче ярдәмче | 2019 – 2025 елларда 8 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 41 454,8 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2019 елда – 5 899,8 мең сум; |

| | |
|---|---|
| программаны финанслау күләмнәре | 2020 елда – 14 089,8 мең сум;<br>2021 елда – 10 732,6 мең сум;<br>2022 елда – 10 732,6 мең сум;<br>2023 елда – 0,0 мең сум;<br>2024 елда – 0,0 мең сум;<br>2025 елда – 0,0 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.<br>Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк»; |

«8 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «8 нче ярдәмче программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр | 8 нче ярдәмче программаны тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттыруга ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>эшләүче яшьләрнең гомуми санынnan «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы предприятиеләренең һәм оешмаларының яшьләр берләшмәләренең мәгълүмат ресурслары язылучылары өлешен 45 процентка кадәр;<br>социаль проектлаштыру, идарә итүне планлаштыру, социаль программалар буенча белем алган предприятиеләрдә һәм оешмаларда эш белән тәэмин ителгән активистлар санын 700 кешегә кадәр;<br>Татарстан Республикасының 100 кешедән артык булган предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшче яшьләр берләшмәләре санын 400 берәмлек күрсәткеченә кадәр;<br>грант нигезендә билгеләнгән тәртиптә федераль, округ, региональ конкурсларда катнашу өчен юнәлдерелгән проектлар санын 500 берәмлеккә кадәр;<br>эшче яшьләрнең гомуми саныннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларында катнаша торган эшче яшьләр өлешен 40 процентка кадәр»; |

8 нче ярдәмче программаның II бүлегендәге җиденче абзацында «2019 – 2022» саннарын «2019 – 2025» саннарына алыштырырга;

8 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. 8 нче ярдәмче программаның
ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

2019 – 2025 елларда 8 нче ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслауның гомуми күләме 41 454,8 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

2019 елда – 5 899,8 мең сум;
2020 елда – 14 089,8 мең сум;
2021 елда – 10 732,6 мең сум;
2022 елда – 10 732,6 мең сум;
2023 елда – 0,0 мең сум;
2024 елда – 0,0 мең сум;
2025 елда – 0,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда ел саен тәгаенләнергә тиеш.

Федераль бюджет, җирле бюджетлар һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы күләмнәре ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.»;

8 нче ярдәмче программаның V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. 8 нче ярдәмче программаның икътисадый,
социаль һәм экологик нәтиҗәлелеген бәяләү

8 ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру 2025 елга түбәндәгеләрне арттырырга мөмкинлек бирәчәк:

эшләүче яшьләрнең гомуми саныннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы предприятиеләренең һәм оешмаларының яшьләр берләшмәләрендә мәгълүмат ресурсларына язылучылар өлешен 45 процентка кадәр;

предприятиеләрдә һәм оешмаларда эш белән тәэмин ителгән, социаль проектлаштыру, идарә итүне планлаштыру, социаль программалар буенча белем алган активистлар санын 700 кешегә кадәр;

Татарстан Республикасының 100 кешедән артык булган предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшче яшьләр берләшмәләре санын 400 берәмлек күрсәткеченә кадәр;

федераль, округ, төбәк конкурсларында грант нигезендә билгеләнгән тәртиптә катнашу өчен юнәлдерелгән проектлар санын 500 берәмлеккә кадәр;

эшче яшьләрнең гомуми саныннан Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеше программаларында катнаша торган эшче яшьләр өлешен 40 процентка кадәр.

8 нче ярдәмче программаны гамәлгә ашыру кысаларында 8 нче ярдәмче программаның үтәүчеләре – команда эшенең гамәлдәге технологияләрен, социаль проектлауны, идарәчел планлаштыруны, электораль активлыкны арттыруны кулланып, яшьләр сәясәте өлкәсендә эшләүче предприятиеләр һәм оешмалар яшьләренең формалаштырылган активы – 8 ярдәмче программасының бурычларын үтәүгә ярдәм итәчәк, Татарстан Республикасында социаль, икътисадый программаларны гамәлгә ашыруны, эшнең адреслылыгын тәэмин итәчәк.

8 ярдәмче программа чараларын уңышлы үтәү түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:

эшләүче яшьләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуны;

республиканың социаль-икътисадый үсешенә юнәлдерелгән проектларда эшләүче яшьләрнең актив катнашуында кызыксынуын;

Татарстан Республикасында уңай демографик тенденцияләрне үстерүне һәм ныгытуны;

яшьләр өчен эшче һөнәрләренең җәлеп итүчәнлеген арттыруны һәм республикадан яшьләрнең миграция агымын киметүне;

дәүләт структураларына халыкның ышаныч дәрәҗәсен күтәрүне.»;

8 нче ярдәмче программага кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин